| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә Африка дуңгыз чумасы барлыкка килү һәм таралу куркынычы янауга бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын бетерү һәм әлеге территорияләрдә кайбер чикләүләр кертү турында

Чувашия Республикасы территориясендә Африка дуңгыз чумасы буенча карантинны бетерүгә бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 31 маендагы 213 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм**:

1. 2016 елның 24 сентябреннән Татарстан Республикасының Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч районнары территорияләрендә (алга таба – куркыныч янаган икенче зона) Африка дуңгыз чумасы барлыкка килү һәм таралу куркынычы янауга бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын бетерергә.

2. 2016 елның 24 сентябреннән 2017 елның 24 мартына кадәр (24 мартны да кертеп) куркыныч янаган икенче зона территориясендә түбәндәге чикләүләрне кертергә:

дуңгызларны, аларны йогышсызландыруны тәэмин иткән 70 °С югарырак температурада сәнәгать җылылык эшкәртүе үткәрелмәгән дуңгызларны чалып җитештерелгән терлекчелек продуктларын читкә чыгаруны тыю;

дуңгызларны сатуны тыю;

халыктан дуңгызлар сатып алуны тыю.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән тыюлар III һәм IV компартментларга караган һәм куркыныч янаган икенче зонадан чыгарылган хуҗалыкларга кагылмый.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә Африка дуңгыз чумасы барлыкка килү һәм таралу куркынычы янауга бәйле рәвештә чикләү чаралары кертү турында» 2016 елның 24 августындагы ПУ-734 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел, 23 сентябрь
№ ПУ-856